**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге башлыгы**

# КАРАРЫ

**25 ноябрь, 2023 ел** **№ 7**

**«Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Түбән Кузмесь авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 5 декабрендә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Түбән Кузмесь авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Кузмесь авылы, Яшел ур., 83А адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

2. 2024 елның 5 декабрендә 17 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Түбән Кузмесь авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Кузмесь авылы, Яшел ур., 83А адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге Түбән Кузмесь авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аталардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Түбән Кузмесь авылының Пионер урамындагы юлны төзү, ремонтлау, карап тоту, вак таш җәю (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эш өчен түләү);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- урам яктырту җайланмасы (урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

5. Нырья авылы башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

6. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы В.И. Павлов